СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 116 12.04.2017
№ _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районының Түбән
Шытсу авыл җирлегенең Генераль
планын раслау турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 елның 21 октябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районында гавами тыңлаулар турындагы нигезләмә нигезендә, җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бәяләмәсен исәпкә алып һәм үткәрелгән ачык тыңлауларның нәтиҗәләре буенча, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Түбән Шытсу авыл җирлегенең Генераль планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы　　　　　　　　Р.Н. Минниханов